DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
абитуриентлар өчен махсус чыгарылыш

# Казан федераль университеты

№ 10 (61)
1 апрель 2013 ел

## КФУ - ул...

*«Һәр юнәлеш буенча югары квалификацияле белгечләр әзерли торган иң яхшы уку йорты. Минем өчен ул, шул исәптән, Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты да, тормышымның аерылгысыз бер өлеше. Студент, спортсмен, өлешчә тренер булуыма да карамастан, уку миңа алга барырга мөмкинлек бирә һәм яңа үрләр яуларга ярдәм итә! КФУ – ул зур тормышка очып күтәрелү юлы»!*

**Ильяс Хөснетдинов**,
Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты студенты, Ушу буенча 11 тапкыр Россия, 5 тапкыр дөнья чемпионы.

*«Минем өчен икенче өй, зур гаилә, ә укытучыларым – туганнарым, дусларым – апа-абыйлар, сеңел-энемнәр кебек. Уку йортымда күп нәрсәгә: үз фикеремне курыкмыйча әйтергә, кешеләр арасында матур тотарга, үз-үземә бәя бирергә өйрәндем».*

**Алинә Солтанова**,
КФУның Яр Чаллы филиалы студенты, «Йолдызлык» фестивале җиңүчесе

*«Бик күп институтларны, студент, укытучылар, хезмәткәрләрне берләштергән гаилә һәм шуның бер вәкиле булу миндә горурлык хисләре уята. Биредә чын студентлар тормышы белән яшиләр: уку, фән, спорт, музыка белән шөгыльләнәләр. Аның ишекләре белемгә омтылган һәр кеше өчен ачык! Безнең сафларга рәхим итегез»!*

**Роза Сәхбетдинова**,
КФУның Алабуга филиалы студенты, РФ хөкүмәте һәм С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия стипендиаты

*Һәр студентны шәхес итеп тәрбияли алырдай, күзгә күренми торган тышча. Университет диварлары арасында илһамлану чыганагы табыла һәм биредә үзеңне тагын да сәләтле итеп сизә башлыйсың. Университет – талантлы көндәшләр күп булган ярыш мәйданы һәм бу табигый көрәштә җиңелүчеләр юк! Һәркем җиңәчәк!*

**Денис Когогин**,
Физика институты магистры, Республикакүләм «Ел студенты - 2012» конкурсы лауреаты, Казан мэры стипендиаты




www.kpfu.ru
чыгарылышның тулы мультимедиа-version
UNIVERSMOTRI.RU рубрика «абитуриенту»

## Хөрмәтле чыгарылыш сыйныф укучылары!

Быел сезгә кеше тормышындагы иң мөһим сайлауларның берсен ясарга кирәк булачак. Ул – оптимистик рух һәм үз-үзегезгә ышанычны саклап, киләчәккә куелган максатларны тормышка ашырырдай һөнәрне сайлау. Ләкин үзегезнең кем булырга теләвегезне аңлау – эшнең яртысы гына. Әле төпле, яхшы сыйфатлы белем бирә торган җирдә укып чыгарга кирәк.

Әгәр үз һөнәрегез буенча уңышларга ирешергә, фәннең иң югары баскычына менәргә телисез икән, Казан университеты нәкъ сезне көтә. Ул үзенә һәрвакыт ныклы белем алырга һәм илебездәге борынгы уку йортларыннан берсенең данлыклы традицияләренә кушылырга теләгән сәләтле һәм актив яшьләрне җәлеп итте. Ике гасырдан артык тарихы булган уку йорты университет мәдәниятен буыннан-буынга тапшыра килүче йөз егерме меңнән артык белгеч әзерләп чыгарды.

Бүген федераль дәрәҗәдәге статус алган Казан университеты икенче мәртәбә туды дип әйтергә мөмкин. Татарстан Республикасының алты вузын берләштереп, ул күппрофильле фәнни белем бирү комплексына әйләнде. Аның составында Яр Чаллы, Алабуга, Яшел Үзән, Чистайдагы филиаллар белән бергә, 19 институт, 26 факультет һәм дүрт югары мәктәп бар. Алар арасында: Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты, Идарә итү һәм территориаль үсеш институты, Икътисад һәм финанс институты, Фундаменталь медицина һәм биология институты, Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты, Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе, Югары банк мәктәбе һәм башка кайбер яңа укыту бүлекләре ачылды. Аларның һәркайсы заманча җиһазландырылып, махсус реконструкцияләнгән корпусларда урнаштырылды: уртак кафедралар, производстволар, кече инновацион компанияләр рамкасында, үз илебезнең генә түгел, чит ил партнерлары белән дә хезмәттәшлек итә.

Бүген, фән, техника үсеше һәм алдынгы производство казанышлары берләшү нәтиҗәсендә, уку йорты әзерли торган белгечләр саны да артты: кара алтын өлкәсе, гамәли информатика, картография һәм геоинформатика, нанотехнологияләр һәм микросистема техникасы, техник физика, бизнес-информатика, социальмәдәни сервис һәм туризм, чит ил төбәкләрен өйрәнү һәм башкалар. Шуңа күрә безнең уку йортында заманча белем бирү өчен генә түгел, ә икътисадта, IT өлкәдә, банк эшендә, идарә итү структураларында эшләү өчен конкурентлыкка сәләтле яшьләрне тәрбияләү мөмкинлекләре тудырылган.

Хәзерге заманда чит тел белмәгән белгечләргә эш табу авыр. Телләр өйрәтүнең сыйфатын яхшырту максатыннан, без, диплом белән беррәттән, халыкара үрнәктәге тел сертификаты тапшыруны барлык институт һәм факультетларга гадәти хәл буларак кертергә омтылабыз. Безнең фәнни китапханәдә дәрәҗәле чит ил басмалары теркәлгән көчле электрон ресурс булдырылды.

Мәктәп укытучысы булырга теләгәннәргә аерым мөрәҗәгать итәсем килә. Бүген укытучыга таләпләр артты. Ул белем дөньясының мәгълүмати киңлегендә яхшы ориентлаша торган, зур методик багажга ия булган әйдәп баручы ролен үти. Казан федераль университеты илдә бөтен фән тармаклары буенча укытучылар әзерли торган иң тулы һәм алга киткән системага ия.

Без булачак мөгаллим, укыту методикасыннан тыш, үз өлкәсе буенча фундаменталь белем алырга тиеш, дигән максатны тормышка ашырабыз. Гомумән алганда, институт һәм факультетларда педагогик белгечлек әзерләүнең өч дистәгә якын юнәлеше бар. Илебездә педагогик белем бирүнең яңа моделе беренче тапкыр Казан университетында кертелде.



Ректор КФУ И.Гафуров студентлар белән

Казан федераль университетында белем бирү фән белән кулга-кул тотынып бара. Шуңа күрә фән, җәмәгать, спорт һәм мәдәният эшләре белән актив шөгыльләнүче, инновацион конкурсларда җиңүче студентларны материаль яктан тәэмин итү өчен күп эш башкарыла. Ел дәвамында фән өлкәсендәге активлыклары өчен студентлар 5 меңнән алып, 25 меңгә кадәр ректор стипендиясе ала.

Сез, хөрмәтле укучылар, Казан университетына Бөтендөнья җәйге студентлар спорт форумы узган елда киләсез. Сезнең булачак өлкәнрәк дусларыгыз Казан үзендә Универсиаданы кабул итсен өчен зур көч куйды. Студентлар спортының халыкара федерациясе бәяләү комиссиясе (ФИСУ) безнең уку йортында спорт тормышының ни дәрәҗәдә югары куелуын берничә тапкыр билгеләп үтте. КФУдан дүрт мең студент, волонтер буларак, аны уздыруда катнашачак. Бу – егерме мең волонтерның һәр бишенчесе безнең студент дигән сүз.

Ә сезгә 2013 елгы Универсиада мирасын җентекләп өйрәнеп калырга туры киләчәк. Университетка аның күп кенә объектлары биреләчәк, шул исәптә читтән килеп укучы студентлар 100% ка тулай торак белән тәэмин ителәчәк. Шулай ук безгә тәгаенләнгән спорт корылмаларында спорт төрләренең егермедән артык секциясе эшли башлады. Аларда дүрт меңнән артык студент шөгыльләнә ала. Сез дә шул сафларга басарсыз дип ышанабыз.

Без Казан федераль университетында укырга, барлык талантларын ачарга һәм көчле шәхес булырга теләгән һәркемне көтеп калабыз. Һәркайсыгызга да дөрес юлны сайлап, аның лаеклы киләчәккә уңышлы адым булуын телим.

**Илшат ГАФУРОВ,**
**КФУ ректоры**

## Укырга ничек керәбез?

**Кабул итү комиссиясенә документларны берничә төрле юл белән тапшырырга мөмкин:**

☛ Шәхсән үзең КФУның кабул итү комиссиясенә килеп (Казан, Кремль урамы, 35 йорт, II корпус, 114, 115, 116 бүлмәләр; ☎ 8(843) 292-73-40, 233-70-76) гариза язарга ▶ http://kpfu.ru/main_page?p_sub=6253;

☛ 25 июльдән дә калмыйча, кирәкле документларның күчермәләрен почта аша юлларга була. Адрес: 420008, Казан, Кремль урамы, 18 йорт, КФУның кабул итү комиссиясе;

☛ гаризаларны 20 июньнән 25 июльгә кадәр ▶ abiturient.kpfu.ru электрон сайты аша да җибәрергә мөмкин.

☛ Сорауларыгыз туса, ☎ (843) 221-34-02 номерына шалтыратып белешә аласыз;

☛ документларның төп нөсхәләрен (аттестат, 3х4 форматындагы 6 фото, ИНН күчерелмәсе, иминиятләштерү таныклыгы, паспорт, полис күчерелмәләре) кабул ителүчеләрнең исемлеге чыкканчыга кадәр дә, исемлек чыккач та китереп бирергә мөмкин;

☛ БДИдан тыш, университетта эчке имтихан тотучылар документларын 10 июльгә кадәр тапшырырга тиеш.

☛ нинди дә булса ташламаларга ия булучылар шәхсән үзләре килергә тиеш!

**Сайтлар юл күрсәтә!**

**Сезгә һәр институт-факультетның сайт адресын тәкъдим итәбез. Тулырак мәгълүматны һәм яңалыкларны сез биредә таба аласыз!**

- Фундаменталь медицина һәм биология институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=213
- Экология һәм география институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=214
- Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=215
- Тарих институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=216
- Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=217
- Физика институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=218
- А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=219
- Юридик факультет ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=220
- Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=221
- Филология һәм сәнгать институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=222
- Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=224
- Икътисад һәм финанс институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=5102
- Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=87
- Педагогика һәм психология институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=88
- Фәлсәфә факультеты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=89
- Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=91
- Идарә итү һәм территориаль үсеш институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=86
- Яшел Үзән филиалы ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=6205
- Яр Чаллы институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=6206
- Алабуга институты ▶ kpfu.ru/main_page?p_sub=6207
- Чистай филиалы ▶ filinch.ru/

## Үсеш юлында – 8 өстенлекле юнәлеш:

- яңа материаллар һәм нанотехнологияләр;
- мәгълүмати-коммуникацион технологияләр;
- биология, медицина һәм тере системалар технологиясе;
- табигатьтән рациональ файдалану;
- күп дәрәҗәле мәгариф системалары, гуманитар һәм педагогик технологияләр;
- мәдәниятара коммуникацияләр, Көнчыгышны өйрәнү, төбәк һәм халыкара мөнәсәбәтләр;
- төбәкнең социаль-икътисади үсеше, алдан күрү һәм идарә итү технологияләре;
- кара алтын-газ технологияләре.

# КФУның белем биру комплекслары

## ФИЗИКА-МАТЕМАТИКА ЮНӘЛЕШЕ

- Физика институты
- Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты
- Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты
- Мәгълүмати Технологияләр һәм Системалар югары мәктәбе (ИТИС)
- IT лицей-интернат

## ТӨГӘЛ ФӘННӘР ЮНӘЛЕШЕ

- Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты
- А.М.Бутлеров ис. Химия институты
- Фундаменталь медицина һәм биология институты
- Физик тәрбия һәм тернәкләндеру медицинасы институты
- Экология һәм география институты

## ИНЖЕНЕРИЯ-ТЕХНИКА ЮНӘЛЕШЕ

- Инженерия институты
- автоматлаштыру һәм энергетика факультеты
- автомобиль җитештеру факультеты
- Төзелеш факультеты

## СОЦИАЛЬ-ГУМАНИТАР ЮНӘЛЕШ

- Идарә иту һәм территориаль үсеш институты
- Икътисад һәм финанс институты
- Җәмгыятьне модернизацияләүнең чагыштырма тикшеренү институты
- Югары банк мәктәбе
- Дәүләт һәм муниципаль идарә иту югары мәктәбе
- Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты
- Филология һәм сәнгать институты
- Педагогика һәм психология институты
- Тарих институты
- Телләр институты
- Массакүләм коммуникация һәм социаль фәннәр институты
- Юридик факультет
- Фәлсәфә факультеты

Кызыл төс белән КФУның принципиаль яңа бүлекчәләре, шул исәптән филиаллар да, билгеләнгән

## КФУның инновацион үсеш юнәлешләре

- Биотехнологияләр, фармацевтика һәм биомедицина
- Нефть табу, нефть эшкәртү һәм нефтехимия
- Мәгълүмати-коммуникацион технологияләр һәм инфроструктура
- Комплекслы социогуманитар тикшеренүләр













## КФУның 2010 һәм 2012 елларда төп күрсәткечләре

**1. СТУДЕНТЛАР** (көндезге һәм читтән торып уку)





**2. АСПИРАНТЛАР**




**3. УКЫТУЧЫЛАР**




**4. УКЫТУ-ЛАБОРАТОРИЯ МӘЙДАННАРЫ**




# Дөньядагы беренче астропарк – КФУныкы!

**Космоска очасыгыз киләме? Ләкин... җаваплар төрле һәм өметсез булырга мөмкин. Бер дә борчылмагыз. Казан федераль университеты безгә зур мөмкинлек бирә. Бик тиздән, туган җиребездә басып торган килеш, космос белән таныша алачакбыз.**

Астропарк Энгельгард исемендәге Астрономик обсерватория территориясендә урнашкан. Биреә 40лап фәнни, мәгариф һәм күңел ачу объекты керәчәк. Шулар арасында иң эресе булып, планетарий санала. Ул үз ишекләрен Универсиадага кадәр ачачак.


Планетарий үзе берничә залдан тора. «Сферия» залы – 150, ә «4D» залы 50 кешене сыйдыра алачак. Юллар гигант АОЭ аббревиатурасы рәвешендә ясалып, хәтта космостан ук күренеп торачак.

Башка планетада гәүдә массагызның күпме икәнен белергә теләр идегезме? Монда сезгә космик үлчәүләр ярдәмгә килер. «Тавыш дулкыны» аллеясында бер-береңә сер сөйләргә мөмкин. Каракаршы урнаштырылган ике тәлинкә тыныч кына әйтелгән тавышны да ишетергә ярдәм итәр, ләкин сезне беркем дә ишетмәс.

Шулай ук йолдызлар, эре галактикалар, кояш системасына багышланган экспозицияләр белән танышырга мөмкин. Тематик аллеялар буйлап йөргәндә, космонавтика тарихы турында кызыклы мәгълүмат алырга, борынгы астрономик инструмент макетларын күрергә мөмкин. Кояш нурлары ярдәмендә учак ягарга, ком, су, кояш сәгате ярдәмендә сәгатьне белергә мөмкин. Космик лабиринт аша үтеп, өлкәннәр балачак хатирәләрен яңарта ала.

Шулай ук Обсерваториядә килеш, сез космосның һәр детален карый аласыз. Моның өчен махсус сканер урнаштырылачак.





UNIVERSMOTRI.RU kpfu.ru/main_page?p_cid=5699&p_sub=9644

# Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты

Җәмгыять үсешенә бәйле булган фәнни-техник прогресс геология фәненең алга китүенә дә йогынты ясый. **Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты «Геология» юнәлеше буенча – геология; экологик геология; геохимия; геофизика; геология һәм яна торган казылма байлыкларның геохимиясе; гидрогеология һәм инженерлык геологиясе белгечләренә, «Кара алтын-газ хезмәте» юнәлеше буенча бакалавриат программасына** абитуриентлар кабул итә. Әлеге дисциплиналардан тыш, уку дәверендә бизнес һәм маркетинг, хокук һәм юриспруденция нигезләренә өйрәнергә була. Шулай ук булачак геологлар укыту базаларында һәм Идел елгасы, Урал, Татарстан, Көнбатыш һәм Көнчыгыш Себер, Якутиянең геологик оешмаларында кыр һәм производство практикалары вакытында тәҗрибә туплый. Институтта халыкара хезмәттәшлеккә дә зур игътибар бирелә. Түбәндәге фәннәрдән БДИ нәтиҗәләре булу шарт: **математика; физика; рус теле.**

## Институтның юнәлешләре:

- Кара алтын-газ геологиясе һәм геохимиясе;
- Эшкәртелмәгән җирләрне тикшерү-эшкәртү технологияләре;
- Кара алтын-газ ятмаларын эшкәртүне модельләштерү;
- Геофизика һәм геомәгълүмати технологияләр;
- Нефть-газның табигый сакланмалары литологиясе һәм физикасы;
- Төбәкара геология һәм файдалы казылмалар;
- Гидрогеология һәм инженер геологиясе;
- Тау токымнарының магнитлык һәм палеомагнитлык күренешләре.





**ИТИС Югары мәктәбе – КФУның иң заманча бүлекләренең берсе. Түбәкнең эре IT-компанияләре, шулай ук Microsoft, HP, Cisco, Oracle брендлары республикабызда IT-белгечләр әзерләүгә алынды.**

## Мәгълүмати технологияләр һәм системалар югары мәктәбе

ИТИСта күбрәк гамәли фәннәргә басым ясала, шуна күрә студентлар практиканы республиканың алдынгы IT-компанияләре һәм IT-паркларда үтә. Югары мәктәптә кафедралар лабораторияләр дип үртелә һәм аларның саны көннән-көн арта. Лабораторияләр әзерли торган проектларда катнашу нәтиҗәсендә, икенче курстан соң, студентларга акча эшләү мөмкинлеге туа. ИТИС Югары мәктәбен тәмамлаган һәр студентка КФУ дипломы бирелә.

**Беренче елны – 40 (30ы ИТ-ПАРК грантын алучылар), 2012 елда 150 (121е ИТ-ПАРК грантын алучылар) кеше кабул ителгән.**

Төп юнәлеше: гамәли информатика. Түләүле курслар да бар: Microsoft, Cisco, Java, кесә телефоннары өчен кушымталар уйлап табу, автор курслары.

### Лабораторияләр:

Exigen Services
Fujitsu GDC – 2 лаборатория
Медицинадагы ИТ (ООО «КИР»)
«Интеллектуаль эзләү системалары һәм семантик технологияләр»
Гамәли семиотика
Samsung Android Lab
MEGA Lab (Мегафон)

### Укыту программалары:

Фундаменталь дисциплиналарны һәм академик программаларны КФУның сертификатлы иң яхшы укытучылары укыта.

Махсус курслар ИТ-белгечләре тарафыннан лабораторияләрдә укыла.

**Хәзерге вакытта КФУ катнашында фән һәм технология юнәлешләре буенча приоритет саналган 29 кече инновацион предприятие оешты:**

- Медицина технологияләре һәм медицина җиһазлары – 5;
- Прибор ясау – 3;
- Мәгарифтәге инновацияләр – 6;
- Мәгълүмати технологияләр – 5;
- Космик системалар – 2;
- Табигатьне рациональ куллану – 2;
- Авыл хуҗалыгы – 3;
- Төзүчелек – 1;
- Яна материаллар – 3.



## Экология һәм география институты

Институт **фәнни үзәкләре, лабораторияләр, практика базалары, метеорологик обсерваториясе** белән дан тота. Студентлар уку белән практиканы берьюлы алып бара. Шулай ук институт «Алабуга» ачык икътисади зона, «Татнефть» ААҖ, Университетның версиада корылмалары төзүчеләре өчен зур фәнни тикшеренүләр үздыра.



Институтны тәмамлаган белгечләр **тирә-якны саклау, экологик куркынычсызлык, табигый ресурсларны рациональ куллану буенча туган проблемаларны, экологик мониторинг, менеджмент, экосистемаларны сәламәтләндерү** методлары өлкәсендәге мәсьәләләрне профессиональ рәвештә хәл итә.

**Гидрометеорология** юнәлеше буенча белем алып чыккан студентлар башкарган хезмәт һәркем өчен һәркөнне кирәк булачак. Алар атмосфераның составын, төзелешен, физика һәм динамикасын, мәгълүмати һәм космик технологияләр ярдәмендә һава торышын өйрәнә.

**Туризм һәм кунакханә** эше белгечләкләрен үзләштергән бакалаврлар проектлаштыру институты һәм компанияләрендә, фәнни-тикшеренү оешмаларында, туристлык агентлыкларында, кунакханә, ресторан комплексларында, музей һәм мәгариф учреждениеләрендә уңышка ирешә ала.

**Педагогик белем бирү юнәлешен** тәмамлаган студентлар ике куян койрыгын тотачак. Көндезге бүлектә берьюлы ике белгечлек алырга була: **география+инглиз теле, география+биология, экология+инглиз теле.**

Әгәр сине табигать кызыксындырса, аның белән бәйле проблемалар борчыса, Җир-анабызны саклауга үз өлешенне кертәсең килсә, Экология һәм география институтына укырга кил. Сине Россиянең генә түгел, чит илләрнең алдынгы уку йортларында стажировка үтү, хезмәт базарында үтемле саналган һөнәрләр, иң матур төбәкләрдә җәйге практика һәм романтик экспедицияләр, әлбәттә инде, онытылмаслык студент еллары көтә.


# Фундаменталь медицина һәм биология институты

Ил күләмендә алдынгы юнәлешләрне булдыру максатыннан, Казан федераль университетында яңа проектлар, идеяләр тормышка ашырыла. Медицина һәм биологик технологияләр аеруча алга киткән өлкәләрдән санала. Бүгенге көндә фундаменталь медицина һәм биология институтында яңа медицина кафедралары ачылды. Татарстанда медицина фәненең алга китешенә КФУда әзерләнгән белгечләр зур йогынты ясаячак. Алар яңа буын табиблары булачак. Әүку йортының югары квалификацияле белгечләр әзерләү өчен бөтен мөмкинлекләре дә бар. Әлеге институт бөтен төр белгечләр буенча табиблар, стоматологлар, табиб-генетиклар, табиб-рентгенологлар һ.б. әзерләүне максат итеп куя. Шулай ук Россиянең 200дән артык медицина оешмаларында, дөньяның иң яхшы фәнни үзәкләрендә стажировка үтү мөмкинлеге дә бар. Шулай ук «ФАРМА 2020» программасын тормышка ашыру кысаларында фармацевтика буенча фәнни-белем бирү үзәге ачылды. Бирегә инновацион дарулар һәм субстанцияләр эшләп чыгару белән шөгыльләнәләр. Бу процесска химия, биология, медицина һәм фарматехнология буенча белгечләр җәлеп ителде.

Фән дөньясында иң мөһим һәм перспектив юнәлешләрнең берсе.

**Гомуми фәннәр комплексында инновацияне алга җибәрә алачак локоматив:**

- физика
- химия
- билогия
- мәгълүмати технологияләр





**Фундаменталь медицина һәм биология институтының агымдагы юнәлешләре:**

- Медицина биохимиясе
- Медицина физикасы һәм биофизикасы
- Медицина кибернетикасы һәм информатикасы
- Гомуми һәм медицина генетикасы
- Медицина химиясе һәм фармакологиясе
- Медицина микробиологиясе
- Клиника эшчәнлеге
- Эксперименталь медицина өлкәсендә санаулы белгечләр - табиблар-тикшерүчеләр әзерләү.



# КФУның фармацевтик кластеры

**«Россия Федерациясенең фармацевтика һәм медицина промышленностен 2020 елга кадәр үстерү һәм аның перспективасы» федераль максатлы программа**



## Чара түбәндәгеләрне күз алдында тота:

- ✔ Заманча дару һәм медицина приборларын ясау өлкәсендә инновацион үзәкләр булдыру
- ✔ Үзәкләрнең саны – 7 (аларның 5се фармацевтикага карый)
- ✔ Чараны гамәлгә ашыру өчен, федераль бюджеттан 17 956 млн. сум бүлеп бирелә.
- ✔ КФУ проектының гомуми суммасы 899 млн. сум хасил итә.

## Фәнни-мәгариф үзәк, тәҗрибә һәм промышленность җитештерү бүлекчәләре:

- ✔ Медицина химиясе бүлеге һәм кафедрасы
- ✔ Фармакология бүлеге һәм кафедрасы
- ✔ Биотехнология һәм биоинженерия бүлеге һәм кафедрасы
- ✔ Ген һәм күзәнәк технологияләре бүлеге һәм кафедрасы
- ✔ Хайваннарны вакытлыча тоту өчен бина
- ✔ Тәҗрибәгә нигезләнгән җитештерүчәнлек: каты дару формалары лабораториясе, сыек стериль һәм стериль булмаган дару формалары лабораториясе, сыек дару формалары лабораториясе, аналитик лаборатория
- ✔ Промышленность җитештерүчәнлеге («Татхимфармпрепараты» ААЖ): чимал җитештерә торган участоклы 2 бүлек, төп нигезне әзерли торган участок, стериль дару формаларын әзерли торган участок һ.б.

# КФУның инженерлык кластеры

Казан федераль университеты үз чикләрен җәелдерүне дәвам итә. 2012 елда аның составына Кама дәүләт инженерия-икътисад академиясе кушылды. Академиянең университет составына керүе инженерия өлкәсендә яңа үсеш юлына чыгарга ярдәм итәчәк. КФУның инженерия кластерын **инженерия институты**, **автоматлаштыру һәм энергетика факультеты**, **автомобиль җитештерү факультеты**, **төзелеш факультеты** тәшкил итә. Кушылу нәтиҗәсендә, КФУның тагын бер филиалы барлыкка килде.

**Инженерлык белемен бирүдә приоритет юнәлешләр:**

- медик-биологик приборлар ясау;
- машина төзү (автомобиль төзү);
- нанотехнологияләр һәм микросистемалы җиһазлар;
- мәгълүмати-коммуникацион системалар һәм җиһазлар;
- радиофизик системалар һәм җиһазлар;
- нефть-газ эше;
- әйләнә-тирә мохитне саклау;
- гидрогеология һәм инженер геологиясе



# А.М.Бутлеров исмендәге Химия институты





Бутлеров А.М. ис. Химия институтын Казан университеты тарихыннан аерып карап булмый. Чөнки уку йорты ачылган 1804 елда ук, Университет Уставы нигезендә, физика һәм математика фәннәре факультеты базасында химия кафедрасын ачу турында фикерләр карала башлый. Бик күп галимнәр бөтен дөньяга билгеле Казан химия мәктәбенә нигез сала. 1929 елда исә әлеге юнәлеш институт статусын ала.

Бүгенге көндә институт югары уку йорты лабораторияләрендә, академик һәм фәнни-тикшеренү институтларында, завод лабораторияләрендә, мәктәп-гимназияләрдә эшләү өчен белгечләр әзерли. Студентлар хокук буенча белем туплый, менеджмент нигезләре һәм этикасы белән таныша, тирәнтен рәвештә чит телләр өйрәнә. Хисаплау техникасы белән эшләүгә әзерләү даими башкарыла. Шулай ук аерым игътибар экология белгечләре әзерләүгә дә бирелә.

## Технологик үзәк

КФУның технологик үзәгендә нефть-химия һәм катализ, югары сыйфатлы нефть һәм нефть эшкәртмәләре лабораторияләрендә технологик блоклар булдыру күз алдында тотыла.

Биредә югары сыйфатлы нефть һәм нефть эшкәртмәләре мәсьәләләрен комплекслы рәвештә чишүгә КФУның геологлары, химик, физик, математик, IT-белгечләре, эколог, икътисадчы һәм юристлары җәлеп ителә.

**А.М.Бутлеров исемендәге ХИМИЯ ИНСТИТУТЫ һәм аның өстенлекле юнәлешләре:**

- яңа материаллар һәм нанотехнологияләр;
- мембрана һәм каталитик системаларны барлыкка китерү технологияләре;
- полимер һәм эластомерларны эшкәртү һәм барлыкка китерү технологияләре;
- тере системалар;
- биокаталик, биосинтетик һәм биосенсорлы технологияләр;
- дәвалау чараларын барлыкка китерү технологияләре;



**ХИМИЯ ИНСТИТУТЫ эшчәнлегендә яңа юнәлешләр:**

**Яңа белгечлекләр:**


- катализ һәм куллану кирәк-яраклары химиясе;
- хемоинформатика;
- медицина и фармацевтик химия.

**Яңа кафедралар:**

- катализ һәм куллану-кирәк яраклары химиясе кафедрасы;
- медицина химиясе кафедрасы;
- мәктәптә химия укытуның теориясе һәм методлары кафедрасы.

**Дөньякүләм дәрәҗәдәге лабораторияләр:**

- рентгеноструктур анализ ясау лабораториясе;
- хемоинформатика лабораториясе;
- яңа дару эшләнмәләре ясау лабораториясе.




## Дөньякүләм проект

Уку йорты дәрәҗәсендәге лаборатория булдыру һәм «Хемоинформатика» буенча магистрлар әзерләү проекты. Страсбург шәһәре университеты (Франция) белән берлектә тормышка ашырыла. Фәнни җитәкчеләре – проф. М.Юсупов һәм проф. Варнек.

**Хемоинформатика (химия+информатика) – мәгълүматлардан белемгә.** Ул химия өлкәсе һәм химия технологиясе белемендә оптималь нәтиҗә чыгару өчен мәгълүматны үзгәрткәндә мәгълүмати технологияләргә нигезләнгән теоретик химия өлеше. Икенче сүз белән әйткәндә, химик мәсьәләләр чишкәндә IT куллану.

**Хемоинформатика:**

- катнашма, реакция һәм ялганмалар турында мәгълүмат базасы: булдыру, мәгълүмат белән эшләү, эзләүне оештыру;
- бирелгән үзенчәлекләргә ия булган ялганмалар структурасы: дарулар, деэмульгаторлар, эреткечләр һәм аның катнашмалары, антипиреннар һәм башкалар;
- химик реакция шартларын алдан әйтү;
- катализаторларны алдан әйтү;
- композит һәм катнашма үзлекләрен оптимизацияләү;
- материал һәм ялганмаларның үзенчәлекләрен алдан күрү: физик, химик, физик-химик, биологик, агулар һәм башкалар.

**Хәзерге вакытта төп куллану даирәсе:**

- Зур фармацевтика промышленносте;
- Химия промышленносте.

**Хемоинформатика хәзерге вакытта нәрсә бирә:**

- дарулар эшкәртеп чыгару буенча чыгымнарны 15-30%ка киметә.

# Филология һәм сәнгать институты

«Ана теле» проекты – татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен оештырылган on-line мәктәп. Әлеге проектны Татарстан белгечләре Educartion First компаниясе белән берлектә гамәлгә ашыра. Һәр теләгән кеше **anatele.ef.com** адресы буенча регистрация үтеп, әлеге система ярдәмендә татар телен өйрәнә алачак. Проект ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов куйган бурычны тормышка ашыруны күз алдында тота. Бу проектны эшкәртүгә КФУның телче-галимнәре, укытучылары күп хезмәт куя. Телгә өйрәтүне тормышка ашыруның тугыз дәрәҗәсе булачак. Бүгенге көндә шуларның өчесе инде әзер, ел дәвамында калганнары да эшләнеп бетәчәк. Һәр дәрәҗәдә сигез бүлек (тема) бар. Алар эченә дүртәр дәрес кертелгән. Дәресләр дидидән катлаулыга таба бара. Һәр дәрәҗәне үзләштергән саен, өйрәнүченең сертификат алу мөмкинлеге бар.



**Татар филологиясе** бүлеген тәмамлаучыларга, укып бетергәннән соң, укытучы һөнәреннән тыш, бик күп мөмкинлекләр ачыла. Аларны бары тик дәрес файдалана белергә генә кирәк. Мисал өчен, уку дәвамында төрле конкурсларда, бәйгеләрдә җырлап, сәләтеннне үстереп килсән, диплом белән бергә **«җырчы»** дигән исемне дә алып чыгуың бик мөмкин. Соңгы елларда бу өлкәдә зур уңышка ирешкән әлеккеге укучыларыбыздан Илназ Бах, Илгәрәй һәм башкаларны санап китәргә мөмкин Вакытында үз-үзен күрсәтә белгән студентларны, укып бетергәч, төрле нәшриятлар, газета-журналлар эләктереп алырга гына тора. Профессиональ язучыларыбыз, драматургларыбызның да күпчелеге - татар филологиясе факультеты студентлары. Шул исәптән телевидение-радиода, конгресста, спорт, театр өлкәсендә дә исемнәре билгеле студентлар шактый. Быелдан филология белән берррәттән, **журналистика, этнодизайн, хореография сәнгате** серләренә дә төшендерә башлыйлар. Шулай ук **кытай теле** дә өйрәтеләчәк.

**Роман-герман** филологиясе бүлегендә укытучылык юнәлеше буенча: **инглиз теле** һәм өстәмә икенче чит тел (**француз яки немец теле**); филология буенча: **инглиз теле һәм әдәбияты, испан теле һәм әдәбият**ы белгечләре әзерләнә. Беренче чиратта, бүлекне тәмамлаучылар үз юлларын төрле мәктәпләр белән бәйли. Хәзерге заманда чит телне камил белү эшкә урнашканда аерым бер таләп буларак бара. Шуна күрә, дәүләт хезмәтенә дә инглиз, немец, француз, испан һәм башка чит телләрне яхшы белүчеләрне чакырып кына торалар. Бүлекнең иң зур плюсы – халыкара **Кембридж** системасына нигезләнгән имтиханнар бирү. Ә Кембридж имтиханнарын тапшыручылар теләсә кайсы чит илгә укырга, эшләргә китә алалар. Укып бетергәннән соң, эш таба алмыйча йөргән студентлар роман-герман филологиясе бүлеге өчен, гомумән, ят күренеш.

**Рус филологиясе** бүлеге студентлары киләчәктә төрле типтагы **мәгариф оешмаларында** эшләү өчен, **филологик, фәнни-тикшеренү, укыту-гамәли** һәм **психологик-педагогик** әзерлек алып чыга. Алар үзләрен социаль-гуманитар, иҗади, мәдәни-агарту өлкәләрендә реальләштерә, әдәби-мәдәни музейларда, китап нәшриятларында, матбугатүзәкләрендә яки реклама агентлыкларында эшлиләр. Бу бүлекне тәмамлаган студентларга Россия шәһәрләрендә генә түгел, чит илләрдә эшләү өчен дә сорау зур. Рус филолгиясе белән берлектә, студентлар **инглиз телен** дә өйрәнә. Рус теле шулай ук чит тел буларак та укытыла.

**Тәрҗемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр** бүлегендә тәрҗемәчеләр ике юнәлештә әзерләнә. **«Филология. Тәрҗемә һәм тәрҗемә белеме»** һәм **«Лингвистика. Тәрҗемә һәм тәрҗемә белеме».** Беренче юнәлештә татар теленнән рус теленә һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү серләрен өйрәтәләр. Студентларга зур мөмкинлекләр тудырыла: җиһазландырылган лингафон кабинетлары, синхрон тәрҗемә класслары, югары дәрәҗәле укытучылар h.б. Алар **Дәүләт Советында, Министрлар Кабинетында, газета-журнал редакцияләрендә** практика үтә. Бу юнәлешне тәмамлап, тәрҗемәче дипломы алганнан соң, белгечләр әдәби һәм синхрон тәрҗемәче, төрле дәүләт оешмаларында тәрҗемәче булып эшли алалар. «Лингвистика. Тәрҗемә һәм тәрҗемә белеме» юнәлешендә берничә чит тел белүче белгечләр (бүлектә **инглиз, алман, француз, итальян, испан телләре** өйрәнелә) әзерләнә. Аларга Татарстанда, Россиядә, һәм башка төрле илләрдә дә ихтыяҗ зур.

**Сәнгать** бүлегендә студентларның фәнни түгәрәкләре, иҗади-экспериментал лабораторияләр, компьютер технологияләре үзәге, **«Tatarstyle»** кием дизайн-студиясе, **«АРТиФАКТ»** факультет гәҗите, музыкаль-педагогик театрлар эшләп килә. Студентлар белем алу дәверендә заман таләпләренә туры килә торган, бүгенге көндә күп кенә рәссамнар, дизайнерлар, рекламачылар, полиграфистлар куллана торган барлык график һәм **музыкаль-компьютер программаларын** да үзләштерәләр, **инглиз телен** өйрәнәләр, төрле **интерьер дизайннары**, **шәһәр архитектурасы, ландшафт объектлары** проектларын төзиләр; **заманча тавыш** һәм **ут эффектларын** кулланып, **спектакльләр, хореографик номерлар** куялар. Кайбер педагогик яисә иҗади оешмалар үзләрен яхшы яктан күрсәтергә өлгергән студентларның диплом алганнарын эшлекле тәкъдим белән көтеп торалар.





**N.B.** Зур оешканлык белән уза торган массакүләм мәдәни һәм спорт чараларын да студентлар һәрвакыт актив катнашып, танылып киләләр. **«Начни с нами!», «Метро», «Сәламәтлек поезды», «Фиеста», «Беренче курслар» көне, «Студентлар язы»** кебек чаралар инде матур бер традициягә әйләнде.

Иҗади осталыкларны үстерү максатыннан оештырылган **«Илһам»** һәм **«Әллүки»** әдәби-иҗат берләшмәләренә йөреп, каләм чарлаган студентларыбыз республикакүләм иҗади бәйгеләрдә һәрвакыт танылып киләләр. Алай гына да түгел, шушы берләшмәләрнең иң актив иҗатчылары - бүген яшь язучылар һәм шагыйрьләр. **«Мизгел»** халык театры исә быел драматург Туфан Миннуллин истәлегенә аның **«Саташу»** спектаклен сәхнәләштерде. Халык иҗатының **«Милли хәзинә»** Идел буе яшьләр конкурс-фестивале дә өченче тапкыр уздырылып, анда Татарстан һәм Россиянең берничә төбәге яшь һәвәскәрләре үзләренең иҗади осталыкларын күрсәтте.





# Көнчыгыш институты

Хәзерге заманда чит телләрне өйрәнү модага әйләнеп бара. Күп тел белүчеләр чит ил кешеләре белән иркенләп сөйләшә, башка ил авторларының әсәрләрен тәрҗемәсез укый ала. Кыскасы, чит телләрне күбрәк белгән саен, мөмкинлекләр дә арта. Өстәвенә без башка илләр һәм халыклар белән мөнәсәбәтләр киңәйгән заманда яшибез. Шуна да бүген «һәр илнең ачкычы – тел, телен белгән ил ачар», дигән халык мәкале бик актуаль.

КФУның Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтында чит телләрне үзләштереп кенә калмыйча, Ерак һәм Якын Көнчыгыш илләренең әдәп, әхлак, тарих, икътисадын да өйрәнәләр. Әлеге институт киң колачлы галимнәр, белгечләр әзерләүне төп максат итеп куя. Аның үсеш программасына Көньяк Азия, Вьетнам, Һиндстан, Пакистан юнәлешендә дә белгечләр әзерләү кертелгән. Һәр белгеч бер Шәрык һәм бер Европа телен белергә тиеш. Әмма бүген, чит илләр белән сәүдә элемтәләре үскән чорда, телләр өйрәнү генә аз. **Башка илләр белән мөнәсәбәткә керү үзенчәлекләренә** халыкара багланышлар һәм дипломатия кафедрасында төшендерәләр. Менә кайда әзерлиләр икән ул чын дипломатларны!

Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтында укучы студентлар даими рәвештә тел, укыту һәм фәнни стажировка үтү өчен, үзе өйрәнә торган тел иленә барып кайта ала. Бу илләр исемлегендә – Кытай (Хунань педагогик университеты), Көньяк Корея (Кукмин һәм Чхонджу университетлары), Марокко (Абд-эль-Малика ас-Саади университеты), Египет (Каир университеты), Төркия (Мармара университеты), Иран, Германия, Франция һ.б. Бу ил университетларында студентларыбыз тәҗрибә туплый, телләрен камилләштерә. Өч-биш ай яки бер ел дәвамында белем эстәп кайтучы шәкертләр саны шактый. Институтны тәмамлаган белгечләр арасында бүген Чит ил эшләре министрлыгында, ТР Министрлар Кабинеты, ТР Президент Аппараты, Казан мэриясендә хезмәт куючылар бар.

Әгәр синең дә чит телләр өйрәнесең, киләчәктә **тәрҗемәче, дипломат** яки **геосәясәт өлкәсендәге белгеч** буласың килә икән, КФУның Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтына рәхим ит!

# Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Быелдан башлап журналистларны Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында әзерли башлыйлар. Бүлекнең исеме генә түгел, җисеме дә үзгәрә. Бу аңлашыла да: журналистлар һәрвакыт хәрәкәттә, эзләнүдә. Әгәр син дә яңа идеяләр белән янасың, иҗадилыгың ташып тора икән, димәк, синең урын монда! Үзеңне белгеч буларак реальләштерү өчен, биредә барлык мөмкинлекләр тудырылган. Тиздән **«Казанская стужурка»** исемле электрон студентлар газетасы чыга башлый. Булачак журналистлар республикабызның төрле газета-журналларында, радио-телевидениесендә практика үтә. Алай гына да түгел, университет бу уңайдан, заманча таләпләргә туры китереп, әлеге институт студентларына тәҗрибә туплау өчен шартлар тудыра. Аның эшчәнлеген Интернет аша күзәтергә мөмкин. Ул тәүлек буе уку йорты яңалыклары, студентлар тормышы белән таныштыра. Студентлар да үзләре әзерләгән тапшыруларны UNIVERSMOTRI.RU телевидениесендә куя ала. идеяләреңне тормышка ашыра аласың, «Казанский университет» газетасы редакциясе, шулай ук безнең газета ишекләре дә һәрвакыт ачык. Димәк, ике куянның койрыгын берьюлы тотарга була. Беренчедән, эш күрсәтәсең, икенчедән, иҗатың белән укытучылар да танышып бара. Моннан тыш, журналистика



кафедрасы Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты белән берлектә **«конвергент журналистикасы»** юнәлеше буенча магистратура ачарга җыена. Бу эш белән бергә, **«Визуаль мәгълүмат үзәге»** дигән лаборатория булдыру буенча да эшләр алып барыла.

Татар журналистикасы кафедрасы каршында **«Төбәк һәм милли журналистиканы өйрәнү»** үзәген оештыру планлаштырыла. Шулай ук **«Татар иҗтимагый-сәяси журналистикасы»** һәм **«Татар телендә телевизион журналистика»** белгечлекләре буенча магистратура ачу да көтелә.

Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты – Татарстанда журналистика буенча югары белемле белгечләр әзерли торган бердәнбер үзәк. Һәм ул үзендә креатив, аралашучан, энергияле, максатчан, шул ук вакытта әдәпле һәм итагатьле яшьләрне көтеп кала!

## Халыкара хезмәттәшлек

**КФУ дөньяның 35 иленнән 90нан артык югары уку йорты һәм фәнни үзәк белән хезмәттәшлек итә:**

- РИКЕН институты, Япония
- Юстус Либих университеты, Германия
- Макс Планк институты, Германия
- Хунань педагогика университеты, Кытай
- INALCO Көнчыгыш телләр һәм цивилизацияләр милли институты, Франция
- Хельсинки университеты, Финляндия
- Лювена Католик университеты, Бельгия
- Стамбул университеты, Төркия
- Гранад университеты, Испания
- Фрибург университеты, Швейцария
- Джеймс Мэдисон университеты, АКШ
- Төньяк Каролина штаты университеты, АКШ

# КФУда укы һәм ике дипломлы бул!

Дөньяви фәннәр белән ничек якынаерга? КФУ студентлары өчен моңдый проблема бөтенләй юк. Ник дигәндә, Казан университетында берничә икеләтә диплом программасы эшләп килә. Икътисадтагы соңгы үсеш юнәлешләре турында белергә Икътисад һәм финанс институты базасында оешкан КФУ – SUNY (Нью-Йорк штатының дәүләт университеты) икеләтә дипломы системасы буенча укыту үзгә ярдәм итә. Financial Services (финанс уңайлыклар) дип аталган белгечлекне сайлаган алты кеше унге укуын төгәлләп, берьюлы ике бакалавр дәрәҗәсен алды. Тагын илләп студент укуын дәвам итә.

Бер елыңны Франциядә үткәрү һәм француз филологиясе өлкәсендә уңыш казану – Филология һәм сәнгать институты студентлары өчен хыял гына түгел! Болар – КФУ һәм «Париж III – Яңа Сорбонна» университетлары хезмәттәшлеге һәм «филологик белем, бакалавриат» дип аталган икеләтә диплом программасы нәтиҗәсе. Хәзерге этапта әлеге дипломга унге 4 кеше ия булды. Бүген Казан университетының француз филологиясе кафедрасының берничә студенты «Париж III – Яңа Сорбонна» университетында белем эсти.

Узган елдан бирле КФУда Страсбург университеты белән берлектә хемоинформатика буенча магистр программасы эшләп килә. Бу программаны уңышлы үзләштергән студентлар да ике – Казан һәм Страсбург университеты дипломнарын алачак. Гомумән, хемоинформатика – химия һәм химик технологияләр өлкәсендәге мәгълүматны оптималь чишелешләр кабул итәрлек белемгә үзгәртеп коруга нигезләнгән теоретик химиянең бер өлеше. Россиядә бу өлкәдәге белгечләрне бары тик Казан университетында гына әзерлиләр!

Быел беренче мәртәбә Идарә һәм территориаль үсеш интитутында Гиссен университеты (Германия) белән берлектә оештырылган «Transitional management» (күчеш чоры менеджменты) магистр программасына студентлар туплау үздырылачак. Авыр вакытларда да яхшы идарә булып калырга өйрәнәсең килә икән, рәхим ит!

КФУ – Идел буе регионында берьюлы ике гыйльми дәрәҗә: Россия һәм RIKEN (Япония, Вако шәһәре) университетының PhD дәрәҗәсен бирә торган бердәнбер югары уку йорты. Беренче тапкыр бу мөмкинлектән КФУ, Физик һәм химик тикшеренүләр институты (RIKEN Япония, Вако шәһәре) аспиранты Александр Бәдретдинов файдаланды. Өч елда ана берничә мәртәбә Казан-Токио арасын узарга туры килде. Ике ил, диссертациянең ике гыйльми җитәкчесе... Нәтиҗәсе дә күз алдында: ул Россиянең физика-математика фәннәре кандидаты исеменә һәм RIKEN университетының PhD дәрәҗәсенә лаек булды.

# Бу исемлекнең дәвамчысы – син!



**Гариф Ахунов** - прозаик, драматург, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе *(Татар филологиясе бүлеге)*



**Нурихан Фәттах** - Татарстанның халык язучысы *(Татар филологиясе бүлеге)*



**Аяз Гыйләҗев** - Татарстанның халык язучысы *(Татар филологиясе бүлеге)*



**Хатыйп Госман** - язучы, әдәбият галиме, педагог *(Татар филологиясе бүлеге)*



**Илдар Юзеев** - Татарстанның халык шагыйре *(Татар филологиясе бүлеге)*



**Миңназыйм Сәфәров** - «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәррире *(Журналистика бүлеге)*



**Илшат Әминов** - «Татарстан - Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең генераль директоры *(Журналистика бүлеге)*



**Римма Ратникова** - ТРның Дәүләт Советы рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе *(Журналистика бүлеге)*



**Ренат Харис** - ТРның халык шагыйре, М.Җәлил һәм Г.Тукай ис. премияләре лауреаты *(Рус филологиясе бүлеге)*



**Рәгъде Халитов** - РФ һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе *(Сәнгать бүлеге)*



**Дамир Натфуллин** - Татарстан мәдәният министрлыгының музей программалары һәм мәдәни туризм бүлеге мөдире *(Педагогика һәм психология институты)*



**Фирая Шәйхиева** – ТР Министрлар Кабинетының ТР халык телләре үсеше һәм мәдәнияте бүлеге җитәкчесе, ТРныд атказанган мәдәният хезмәткәре *(Рус филологиясе бүлеге)*



**Айдар Фәйзрахманов** - Татар Дәүләт опера һәм балет театры солисты, ТРның Дәүләт фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе, ТРның халык һәм РФның атказанган артисты *(Сәнгать бүлеге)*

## Мәктәп укучылары – студентлар?

### IT ЛИЦЕЙ-ИНТЕРНАТ



IT лицей-интернат – КФУ базасында сәләтле балалар өчен оештырылган структур үзәк. Монда республиканың төрле районнарыннан һәм Идел буе округыннан килгән балалар укый.

Лицей барлыгы 360 укучыга исәпләнгән. 2012-2013 уку елында 7нче сыйныфка 144 укучы кабул ителде. Алар монда 11нче сыйныфка кадәр белем алачаклар. Беренче чыгарылыш 2017 елда булыр дип көтелә.

### КЕЧЕ УНИВЕРСИТЕТ

Кече университет – вузга кадәр белем бирү үзәге. Аның максаты: балаларның иҗади һәм эзләнү эшчәнлеген үстерү. Ел саен университетның 7 бүлегендә барлыгы 500гә якын бала белем ала. Укыту программасына лекцияләр, практик дәресләр, тренинглар һәм консультацияләр кертелгән. Олимпиадаларга әзерләнү һәм эзләнү төркемнәре эшли. Укучыларга Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәгә йөрергә мөмкинлек бирелә.



**Кече университетның бүлекләре:**

- Физика-математика
- Астрономия
- Химия-биология
- Филология
- Җәмгыять белеме
- Психология
- Тел мәктәбе

### БАЛАЛАР УНИВЕРСИТЕТЫ



КФУның Балалар университеты эшчәнлеген 2011 елның октябрь аенда башлап җибәрде. Бу проект 8 яшьтән алып 12 яшькәчә балалар өчен каралган. Өйдә әти-әниләр аңлатып бирә алмаган һәм мәктәптә дә ачыклык кертелмәгән сорауларга җавапларны укытучылар үзенчәлекле лекцияләр аша балаларга җиткерә. Мәсәлән, «Йолдызлар нигә атыла?», «Кешеләр нигә ярлылар һәм байларга бүленә?», «Йокларганда нигә төш күрәбез?» һ.б.

Балалар университеты – чын мәгънәсендә белемнәрнең артуына һәм системалашуына китерә торган структур үзәк. Лекцияләр тематикасы бик киң: тарих, математика, физика, астрономия, химия, география, психология, медицина, рус һәм чит ил әдәбияты, икътисад, хокук, музыка, архитектура, археология h.б.

# Белмәгәннең башы авырта!

**Син Казан федераль университетына укырга керергә яисә аның эшчәнлеге белән һәрдаим кызыксынып торырга телисеңме? Алайса, түбәндәге мәгълүмат нәкъ синең өчен! Уку йорты, аның структурасы, фән өлкәсе, мәдәни тормышы, спорт һәм башкалар турында барысыннан да алда белеп тор!**

### Университетның рәсми сайты

Әгәр сезгә тиз арада гына университет белән бәйле телефон номеры я булмаса e-mail кирәк, яисә бездә үтәчәк вакыйгалар белән кызыксынасыз икән, Интернеттан www.kpfu.ru адресын җыегыз. Биредә сез иң соңгы һәм дөрес яңалыклар, хәбәрләр белән танышырсыз. Казан федераль университеты турындагы иң соңгы мәгълүматлардан хәбәрдар булырсыз, университет тормышының үзәгендә кайнарсыз.

### КФУның Матбугат үзәге



Матбугат конференциясе, пресс-кит, медиа-план... Бу сүзләр күпләргә, бәлки, теория аша гына таныштыр, ә матбугат үзәгендә исә сез алар белән гамәлдә таныша аласыз. Сезгә студентларның PR-агентлык эшчәнлегендә катнашырга тулы мөмкинлекләр бар. Матбугат үзәге хезмәткәрләре шәһәр, республика газеталары битләрендә, телевизор экраннары, Интернет челтәрләре аша университет абруен күтәрү юнәлешендә эшли, киң җәмәгатьчелек белән элемтәләрне җайга сала, PR-акцияләр оештыра. Мәкалә, пресс-релизлар язарга өйрәнәсегез, эшлекле сөйләшү, әңгәмә кору технологияләренең асылына төшенәсегез килсә, матбугат үзәге нәкъ менә сезнең өчен.

### Татар яшьләренең «DARELFӨNYN» газетасы

«DARELFӨNYN» – университет тормышын, галим-мөгаллимнәр, студентларның уй-фикерләрен туган татар телебездә чагылдырган көзге ул. Яше буенча университет күләмендә барысыннан калышса да, мәгълүмат җәһәтлеге һәм татар телле укучыларны берләштерү ягыннан алда бара. «DARELFӨNYN» газетасы «Ел студенты – 2012» республикакүләм бәйгесендә «Иң яхшы массакүләм матбугат чарасы» номинациясендә төп җиңүче булды. Атнага бер мәртәбә дөнья күрә торган газета битләрендә сезне мавыктыргыч язмалар көтә. Интернет челтәрендә дә яңа саннар белән таныша аласыз. kpfu.ru/main_page?p_sub=6451 сылтамасына керү – «DARELFӨNYN»гә эләгү дигән сүз. Редакция вәкилләре сәләтле, язу-сызуга һәвәс яшьләрне бик теләп һәм яратып үз сафларына алырга әзер!

### КФУның «Казанский университет» газетасы

Әлеге газетаны, чын мәгънәсендә, университетның елъязмасы дияргә була. Газетага шулай ук теләгән һәр кеше яза, фикерен белдерә, университет тарихын теркәүгә үз өлешен кертә ала. Атнага ике мәртәбә чыга торган газета белән Интернет челтәрендә kpfu.ru/main_page?p_sub=6212 адресына кереп танышырга да мөмкин. Әгәр университет тарихын язышуда үзегезнең яңа алымнарыгыз, теләгегез бар икән, редакция ишекләре сезнең өчен һәрвакыт ачык. Университетыбыз газетасын бергә гамәлгә кертик.

### «UNIVER TV» телевидениесеннән

сез университет кысаларында уза торган чаралар турында видеомәгълүмат ала аласыз. Телевидение хезмәткәрләре Казан студентлары турында гына түгел, ә бөтен Рәсәй, хәтта дөнья күләмендәге уку йортлары турында сюжетлар әзерли. Һәр көнне «Univer news» мәгълүмати программмасы эфирга чыга. Әлеге телепрограмма аша сез кафедра, бүлекләрдә, факультет, институтларда һәм, гомумән, университетта нiләр булганын белә аласыз. «Фильмнар, әңгәмәләр» сәхифәсендә университет, укытучылар тормышы тулырак чагылыш таба. Абитуриентлар өчен махсус «Абитуриентка» сәхифәсе бар. Биредә үзегезне кызыксындырган барлык сорауларга җавап таба аласыз. «БДИга әзер бул» сәхифәсендә видеодәресләр урнаштырылган. «UNIVER TV» хезмәткәрләре әзерләгән материаллар ярдәмендә сез имтиханга әзерләнә аласыз. Тапшырулар һәм барлык язмалар .kpfu.ru/main_page?p_sub=6211 сайтына урнаштырылган. Телевизион тапшырулар эшләүдә син дә катнаша аласың! UNIVERSMOTRI.RU

# Кайсы һөнәрләр кирәгрәк?

**2013 елда иң кирәкле һөнәр ияләре инглиз телен белгән менеджерлар, программистлар һәм техник белгечләр булачак. «Анкор» кадрлар холдингы белгечләре әнә шундый фараз ясаган.**



Быел, башка еллардагы кебек үк, сәнәгать өлкәсендә, ягулык-энергетика комплексында, автомобиль төзелешендә эшче кадрларга кытлык булачак. Әзерлекле һәм тәҗрибәле белгечләргә өстенлек бирелачәк. Шулай ук 2013 елда IT-һәм веб-программистлар, кунаклар кабул итү тармагы белгечләре, югары технологияле җитештерү өлкәсендә квалификацияле белгечләргә, инглиз телен камил белгән менеджерлар, төзәк һәм сәүдә вәкилләре, сату бүлеге җитәкчеләре һәм техник белгечләргә сорау аеруча зур булачак.

Кадрлар базарын өйрәнүче тагын бер оешма – «SuperJob» компаниясе хәбәр иткәнчә, гыйнвар аенда декабрь белән чагыштырганда иминиятләштерү белгечләренә (+37,9% вакансия), сатып алу өлкәсе белгечләренә (+30%), бухгалтер һәм финанс белгечләренә (+18,4%) сорау арткан. 2012 ел ахырында яңа хезмәткәрләрне күбесенчә эре оешмалар эзләсә, 2013 елда яңа хезмәткәрләр эзләүчеләрнең күпчелеге – зур булмаган оешмалар. Транспорт, логистика һәм тышкы икътисад өлкәсендә югары идарәче вазыйфаларына сорау арткан. Шулай да мондый төр вазыйфаларга иң зур сорау сәүдә өлкәсендә күзәтелә.

**Мәгълүмат «Ватаным Татарстан» газетасыннан алынды**

# Заманча «авыл»!

**Студентлар кайда яши? Әлбәттә, тулай торакта! Казан федераль университеты тулай тораклары Пушкин, Кызыл Позиция, Гадел Кутуй, Бутлеров һәм Парин урамнарында урнашкан. I курска килүчеләрне, гадәттә, Универсиада авылы (Парин урамы) көтә. Студентлар тулай торак белән 100% тәэмин ителә.**




Академик Парин урамында урнашкан «авыл»да йортларның эче бик матур, якты, кондиционер бар, җиһазлар яңа, пластик тәрәзәләр тавыш үткәрми, лифт эшли. Бүлмәләрдә 2-3 кеше яши. Һәркайсында душ бар. Аш бүлмәсе 3-4 бүлмәгә бер туры килә. Интернетка керү өчен мөмкинлекләр каралган. Куркынычсызлык өчен дә борчылыр урын юк: коридорлар видеокамера белән тәэмин ителгән. Тулай торак билгеле бер вакытта бикләнә. 11 дән 6 га кадәр шаулап йөрергә ярамый.

Бассейнга, тренажёр залларына йөрергә, кыш көне тимераякта шуарга (ишегалдында), ә җәй көне велосипедта, роликларда йөрергә (кулланып торырга бирәләр), теннис, футбол уйнарга була. Һәр бәйрәм саен, төрле кичәләр, психолог, мәртәбәле кунаклар белән очрашулар, дискотекалар үткәрәләр.



## Матурлык салоны

Казан федераль университеты студентлары һәрьяктан камил булырга тиеш. Матурлык һәм пөхтәлек ягыннан бигрәк тә. Ә Универсиада авылында яшәүчеләр хәзер үз матурлык салонына йөри. Вуз җитәкчелеге алар өчен Яңа елга зур бүләк ясады. Матурлык салонында чәчтарашханә хезмәтләре күрсәтеләчәк. Заллар, традицион рәвештә, икегә бүленгән: егетләр һәм кызлар өчен. Һәркайсында ике урын бар. Салонда шулай ук массаж кабинеты бар, косметологик хезмәтләр күрсәтелә, тырнак сервисы һәм солярий эшли.





## Супермаркет

Студентларга көнкүреш кирәк-яраклары, азык-төлек товарлары сатып алу өчен, әллә кая барып йөрисе булмаячак. Универсиада авылы территориясендә ачылган супермаркетта бөтен әйбер бар! Бәяләре дә кыйммәт түгел. Ә такталарда товар исемнәре өч телдә: рус, инглиз һәм татар телләрендә язылган.



## Медицина үзәге

Хәзер студентларга сәламәтлекләрен тикшертү өчен ерак барасы юк. Универсиада авылында Медицина үзәге ачылды. Экспертлар аның эшчәнлеген чит илләрнекеннән дә югарырак бәяли. Регистрация ике информат белән җиһазландырылган: алар ярдәмендә, табибка керү өчен, электрон чиратка язылырга, белгечләр турында тулы мәгълүмат алырга мөмкин.



Үзәктә тикшерену өчен бөтен методлар кулланыла: заманча җиһазландырылган эндоскопия, флюорография, терапия, УЗИ, рентген, хирургия һәм травматология кабинетлары. Шулай ук көндезге стационар, физиотерапия, нурлы диагностика бүлекләре эшли. Һәркайсы пациент таләпләрен исәпкә алып эшләнгән.





## Даруханә

Универсиада авылында 24 сәгать буе эшли торган даруханә бар. Биредә чит илнекеләр белән бергә, Татарстанда җитештерелгән даруларны алырга мөмкин.



# Спорт сөючеләр өчен

**Республикабызда спортка зур игътибар бирелә. Яшь буынны рухи яктан гына түгел, ә тән ягынна да сәламәт итеп тәрбияләү өчен, җитәкчелек бик күп мөмкинлекләр тудыра. Казан федераль университеты базасында гына да 11 спорт объекты бар. Укудан буш вакытны заманча тренажерлар белән җиһазландырылган залларда шөгыльләнеп, физик халәтеңне ныгытырга, яңа үрләр яуларга мөмкин..**

## «Уникс» спорткомплексы

**(Нужин ур., 2, тел.:238-40-68)**

Бирелә физик тәрбия һәм сәламәтләндерү буенча өстәмә хезмәтләр күрсәтелә. Аэробика, бодифлекс, йога, пилатес, шейпинг, бию класслары, кыяга менү, тай-бо, тренажёр залларында иң яхшы инструкторлар яңа программалар тәкъдим итә. Чиста чишенү бүлмәләре, душ, сауна, унай дәресләр тәртибе – һәммәсе спорт сөючеләр өчен. Моннан тыш, медицина-фитнес лабораториясендә компьютер тестлары ярдәмендә сәламәтлекне тикшерергә һәм аерым киңәшләр алырга мөмкин. КФУ хезмәткәрләре, студентлар (нинди вузда һәм нинди бүлектә укуына карамастан), укучылар һәм лаеклы ялдагылар өчен 25% ташлама каралган.

## «Бустан» универсаль спорткомплексы

**(В.Кулагин ур., 8а, тел.: 221-04-11)**

Комплекс гомуми мәйданы 3499 һәм 6196 кв.м зурлыкта булган ике бинадан тора. Бирелә универсаль спорт һәм тренажёр залы, йөзү бассейны, шулай ук медицина һәм административ блоклар бар. Быел узачак Җәйге студентлар Универсиадасында спорткомплекста волейбол буенча кайбер ярышлар үткәрелер дип көтелә. Йөзүчеләр өчен тренировкалар үткәрелячәк. КФУ хезмәткәрләренә тренажёр залында шөгыльләнү өчен 50% ташлама бирелә. Шулай ук хезмәткәрләр якшәмбе көнне көнгезге өчтән дүрткә кадәр бассейнда бушлай йөзә ала.

## «Буревестник» спорткомплексы

**(Җиңү проспекты,49. тел.: 221-09-25)**

«Буревестник» спорткомплексы Универсиада авылында урнашкан. «Оргсинтез»дан соң зурлыгы буенча икенче урында торган йөзү бассейнының озынлыгы 50 метр. Бирелә иртәнге 6.15 тән кичке 10 га кадәр шөгыльләнергә мөмкин. Бәяләр чагыштырмача кыйммәт түгел. Спорткомплекста йөзәргә өйрәнү, уен һәм тренажер заллары да бар. 24х12 метр зурлыктагы йөзәргә өйрәнү залында суда үзенне тоту техникасының асылына төшенергә, төрле күнегүләр ясарга ярдәм итәләр. Тренажер залы да заманча таләпләргә туры китереп җиһазландырылган. 36х24 зурлыгындагы уен залы исә универсаль. Бирелә волейбол һәм баскетбол уйнарга мөмкин. Тагын шунысы мөһим: «Буревестник» спорткомплексы Универсиада авылында яшәүче студентларның янәшәсендә генә урнашкан.

## «Мәскәү» спорткомплексы

**(Мәскәү ур., 49, тел.: 237-68-50)**

Корылманың гомуми мәйданы 5148 кв.м тәшкил итә. Бирелә спорт залы, тренажёр, көрәш белән шөгыльләнү заллары, аэробика, авыр атлетика, шулай ук медицина һәм административ бүлмәләр бар. Җәйге Универсиада вакытында волейбол буенча күнегүләр уздырылачак. КФУ хезмәткәрләре өчен тренажёр залына 50% ташлама каралган.

## «Теннис академиясе»

**(Оренбург тракты, 101, тел.: 221-67-81)**

«Теннис академиясе» – Казан шәһәре халкы өчен ишекләрен ачкан Универсиада объектларының берсе. Мәйданы 8,5 га булган комплекс эчендә йөри торган трибуналы 8 ябык һәм 18 ачык теннис корты бар. Төп ачык кортта уен барышын – 3 мең, ә кече трибунада 1 мең тамашачы күзәтә ала. 19,5 кв.км мәйдан биләп тора торган академиядә күнегүләр өчен 8 корт урнаштырылган. Уен барышын 3200 кеше – төп аренада, 400е икенчесендә күзәтә ала. Бирелә ел саен «Казан Кремле Кубогы»на ярышлар уздырыла. Бөтендөнья Җәйге студентлар Универсиадасы вакытында теннис һәм бадминтон буенча ярышлар үтәчәк.


**КФУ спортчылары үз уку йортын дөнья күләмендә танытү өчен, бөтен көчләрен куя. Алар Кытайның Шенчьжэнь шәһәрендә узган дөньякүләм универсиада, Көньяк Кореянең Дэгу шәһәрендә узган җиңел атлетика буенча Дөнья чемпионатында, Бөекбритания башкаласы Лондонда үткән Олимпия уеннарында җиңү яулады.**



**Алексей Обмочаев** – Лондонда узган Олимпиаданың волейбол уеннарында алтын медаль иясе.




**Юлия Зарипова** – Лондондагы Олимпиаданың киртәле йөгерү ярышларында алтын медаль иясе.



**Андрей Деманов** – авыр атлетика буенча 2011 елның Европа Чемпионы, Шенчьжэнь Универсиадасында алтын медаль иясе








*N.B.*

**Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты** ишекләре спорт сөючеләр өчен һәрвакыт ачык. Институтны тәмамлаган студентлар **физик тәрбия һәм тормыш иминлеге укытучысы, спорт белгече** булып чыга. Шулай ук биологик белем (физиологик аспектта) бирелә.

Бинада гомуми һәм индивидуаль дәресләр өчен аудиторияләр бар. Практиканы студентлар урта гомуми белем бирү учреждениеләрендә, балалар һәм яшьләр өчен урта мәктәпләрдә, «Динамо», «Рубин», «Зенит» кебек спорт оешмаларында үтә. I һәм II курс студентлары өчен «Ядчик» укыту-сәламәтләндерү үзәгендә дәресләр уздырыла.

Студент елларында ук зур үрләр яулап, ил күләменә танылу турында кем генә хыялланмый икән?! КФУда спортка, сәламәт яшәү рәвешенә игътибар аеруча зур. Ә Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институтын тәмамлаучыларның күбесе, диплом алганда, **Татарстан, Россия,** хәтта **дөнья чемпионы** дәрәҗәсенә ия була.

Схема 1.
КФУ филиаллары




**Алабуга институты**
*ТР Алабуга ш., Казан ур., 89*
kpfu.ru/main_page?p_sub=6207

**Чистай филиалы**
*ТР, Чистай ш. Студентлар,ур. д.15* filinch.ru

**Яр Чаллы институты**
*Яр Чаллы ш., Тынычлык пр., 68/19*
kpfu.ru/main_page?p_sub=6206

**Яшел Үзән филиалы**
*Яшел Үзән ш., С.Сәйдәшев ур.,4,*
kpfu.ru/main_page?p_sub=6205

Схема 2.
Казан шәһәрендә КФУ төп биналарының урнашу тәртибе

**КФУ ның төп бинасы,** *Кремль ур., 18*
**Фундаменталь медицина һәм биология институты, Юридик факультет**

**А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты,** *Лобачевский ур., 1/29*

**II корпус** *Кремль ур., 35*
**Кабул итү комиссиясе, Экология һәм география институты, Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты,**

**Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты, Мәгълүмати системалар һәм технологияләр югары мәктәбе**
*Проф.Нужин ур., 1/37*

**УНИКС мәдәни-спорт комплексы**
*Проф.Нужин ур., 2*

**Тарих институты**
*К.Маркс ур., 74*

**Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты**
*Товарищеская ур., 5*

**Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты,** *Кремль ур., 4/5*

**Идарә итү һәм территориаль үсеш институты,** *Кремль ур., 6/20*

**Физика институты** *Кремль ур., 16*

**Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты,** *Сул Болак ур., 44*

**Педагогика һәм психология институты,** *Межлаук ур., 1*

**Филология һәм сәнгать институты,** *Межлаук ур., 3/45*

**«Мәскәү» спорткомплексы,** *Мәскәү ур., 49*

**Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты,** *Пушкин ур., 1/55*

**Фәлсәфә факультеты,** *Пушкин ур., 1/55*

**Филология һәм сәнгать институты,** *Татарстан ур., 2*

**Икътисад һәм финанс институты,** *Бутлеров ур., 4*

**Инженерлык институты** *ул. Сайдашева, 12*

**«Бустан» спорткомплексы, «Бустан» бассейны,** *Кулагин ур., 8а*

**Универсиада авылы, «Буревестник» бассейны, Теннис академиясе**

Универсиада авылына бару схемасы (47 нче номерлы маршрут)




Казан федераль университеты
«DARELFƟNYN» газетасының махсус чыгарылышы

Мөхәррир – Илдар Азат улы Кәримов
Иҗат коллективы: Д.Р.Миннекаева, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева, Л.Х.Исхакова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева
Фотохәбәрчеләр: А.Сатонина, А.Галимуллина, Ә.Фазлыйәхмәтов, С.Тябин, Р.Гыйниятов, Ю.Карпова
Газета бушлай таратыла Тираж 1500

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00. «Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.